**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2022 елның «12» маеннан № 149

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрлары планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә юлламасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 01 сентябрендәге 359 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрлары планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә юлламасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 01 сентябрендәге 359 номерлы карарының 2.5 бүлегенең 2.5.1. пунктын түбәндәге эчтәлекле 8 пунтча белән тулыландырырга:

«8) бер рәттә блокировкаланган барлык йортларның хокук ияләренең,

блоклы төзелештәге бер йортны реконструкцияләгән очракта, ризалыгы.»;

1.5 пунктның 3 абзацында «өлешләп төзүдә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча гавами-хокукый компания» сүзләрен «территорияләрне үстерү Фонды халык-хокукый компаниясе» һәм» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://www.novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов